# ТЫЛСЫМЛЫ АҺӘҢ

*Шарифуллина Гульнар Абузаровна, 51 год. Заведующая Верхнешитцинским сельским домом культуры, д.Верхние Шитцы Сабинского района Республики Татарстан*

Җирдә кеше яшәп китә икән,
Агылып калсын моңы йөрәктән.
Моңлы бала гына көчле була,
Батыр була ала кирәктә...
Лена Шагыйрьҗан

Лена Шагыйрьҗанның бу шигырь юлларын алуым очраклы гына түгел. Хезмәтебез җыр-моң белән, халкыбызның моңын, җырларга салган күңел халәтен, гореф-гадәтләрен, музыка уен коралларын балаларга кече яшьтән җиткерү белән бәйле. Мәдәният йортыбызда күп еллардан бирле эшләп килүче, бүгенге көндә Үрнәк коллектив исемен йөртүче “Дубая” халык уен кораллары ансамбленә йөрүче балалар белән күп төрле музыка уен коралларын үзләштерәбез. Әйе, өйрәтәбез дип кенә әйтү дөрес тә булмас иде, чөнки яңарак булган инструментларны балалар белән бергә өйрәнәбез. Курай, кубыз, сорнай, бәрмә уен кораллары, таш сыбызгы, тальян, салам курайлар янына гөслә дә өстәлде. Безнең якларда уйналган, дигән мәгълүмат тә булмаган гөсләгә килүнең юлы ничегрәк булды соң?

“Дубая” ансамблебезенең җитәкчесе, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Илшат Шарифуллин үзенең истәлекләре белән уртаклаша: “Миңа 6-7 яшьләр чамасы булгандыр, әти Сабадан китап зурлыгында, турыпочмаклык формасында уенчык гөслә алып кайтты. Аның гөслә икәнен дә белмибез, әти аңлатып, бу “уенчык”ның бик үзенчәлекле, кадерле уен коралы икәнен аңлатты. Ул вакытта минем гармунда уйнарга өйрәнә башлаган вакыт, бу гөсләдә дә уйнап карау теләге туды. Аның көйли торган ачкычы булуын да хәтерлим, шуның белән көйләп, әти көй дә чыгарды. Аннан без дә тырыша торгач, “Әнисә” көен  уйный алдык. Ул уенчык булса да, бер уен коралында да булмый торган тавыш чыгара, һәр кылын берьюлы сыпырып төшсәң, әкияттән геройлар килеп чыккандагы шикелле аваз чыгара иде. Бу балачак хатирәсе инде күптән онытылып, хәтер төпкеленнән менә шушы гөслә белән кызыксына башлагач кына калыкты”.

Хәзерге гөсләгә юл нәкъ менә балачактан башлангандыр кебек. Мәктәп яшендә рус әдәбиятыннан гына укып, рәсемнәрдән генә күреп белгән гөсләне татар гөсләсе буларак ансамбльдә куллану безнең өчен чын

могҗизага тиң. Чөнки әле безнең Саба якларында гөсләчеләр, гөсләләр булганмы, ул турыда да әлегә мәгълүмат юк.

Моннан берничә дистә ел элек районыбызда “Иске Казан түгәрәк уен” фестивале кысаларында булган чарада Мари Иленең Йошкар-Ола шәһәрендә эшләп килүче «Татар мәдәни үзәгенең» сәнгать җитәкчесе, Мари Иле һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гәрәй Мәгъсүмҗанов гөсләбелән чыгыш ясады. Беренче тапкыр гөсләне шул вакытта күрдек, аның үзенчәлекле тавышы күңелгә кереп калды. Чөнки Гәрәй абый гаҗәеп осталык белән татар халык көйләрен бер – бер артлы тезде генә. Шуннан бирле инде гөслә ешрак күренә башлады, бәйгеләр оештырылды. Гөсләдә уйнаучы Арча, Балтач ягы осталарын таный башладык. Гәрәй абый белән, шулай ук фольклорист, этнограф, Татарстан  Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, гөсләләр ясаучы Геннадий Михайлович Макаров белән дә якыннан танышу, аралашу бәхете елмайды. Гәрәй абыйның да гөсләдә уйнаучы гына түгел, аны ясаучы оста икәнен дә белдек. Һәм гөсләне үзебездә булдыру хыялы белән яна башладык.

Ниһаять, 2017 елда районыбыз, мәдәният бүлеге җитәкчелеге ярдәме белән безнең хыял чынга ашты, Гәрәй абый Мәгъсүмҗанов ясаган ике гөсләгә ия булдык. Аннан Гәрәй абыйдан киңәшләр алып, үзлегебездән өйрәнә башладык. Татар гөсләсенең төрлечә көйли алу мөмкинчелегенә ия һәм пентатоникага көйләнүе, шунлыктан татар халык көйләрен уйнап булуы да ачыкланды. Гөсләнең яңгырашы чынлап та һәркемне әсир итәрлек. Ул ниндидер әкияти дөньяга, тылсым иленә алып кереп китә, тыңлаган саен тыңлыйсы килә. Татарларда гөслә электән үк кулланышта булган. Ул җырчыларга, бәет, мөнәҗәт әйтүчеләргә кушылып уйнау, шулай ук инструменталь көйләр башкару өчен дә кулланылган икәнен белдек, һәм әкренләп балалар да гөсләдә уйнарга тартылдылар. Алар зур кызыксыну белән үзләштерә, гөсләгә кушылып җырлап та карыйлар. Конкурс – фестивальләрдә катнашу мөмкинлеге дә ачылды, ансамбль белән гөслә юнәлешендә дә уңышларга ирешә башладык. Алга таба да бу эшне туктатмыйча, гөслә серләренә төшенүне максат итеп куйдык.

Гөсләнең сихри тавышы әби – бабаларыбыз яшәгән чорлар белән тоташтыра, аларның моңын тоярга, уйланырга да этәрә кебек. Ә балаларның шушы тылсымлы аһәңне аңлавы, гөслә моңына гашыйк булуы киләчәккә өмет, Лена Шагыйрьҗан шигырендәгечә, яшь буынның кыю булып үз халкының буыннан буынга күчә баручы ядкәрләрен саклавына ышаныч уята.

# ВОЛШЕБНАЯ МЕЛОДИЯ

Җирдә кеше яшәп китә икән,
Агылып калсын моңы йөрәктән.
Моңлы бала гына көчле була,
Батыр була ала кирәктә...
Лена Шагыйрьҗан

Не случайно я брала эти стихотворные строки поэта Лены Шагирзян. Труд наш связан с музыкой – с тем, чтобы с малых лет передавать детям мелодию, традиции, музыкальные инструменты, заложенные в песнях нашего народа. С ребятами ансамбля народных инструментов “Дубая”, который существует в нашем доме культуры уже много лет и сегодня носит название Образцового коллектива, мы осваиваем различные музыкальные инструменты. Да, было бы неправильно говорить, что мы учим, потому что вместе с детьми изучаем новые инструменты. К кураю, кубызу, ударным инструментам, каменному свистку, тальянке, соломенному кураю добавились гусли. Каков же был путь к гуслям, о которых в наших краях не было даже никаких сведений?

Руководитель ансамбля “Дубая“, заслуженный работник культуры Республики Татарстан Ильшат Шарифуллин делится своими воспоминаниями: «Мне было около 6-7 лет, когда отец привез из Сабов (районного центра) игрушечные гусли размером с книгу, прямоугольной формы. Не зная, что это были гусли, отец объяснил, что эта «игрушка» – очень своеобразный, дорогой инструмент. Тогда я начал учиться играть на гармошке, и мне захотелось попробовать поиграть и на этих гуслях. Помню, у них был специальный ключ для настройки. Потом мы смогли сыграть мелодию татарской народной песни «Аниса». Хотя это была игрушка, она издавала нежный, сказочный звук».

Кажется, путь к нынешним гуслям начался именно с детства. Для нас настоящее чудо – использовать в ансамбле гусли, о которых в школьном возрасте читали только по русской литературе и знали только по рисункам. Ведь до сих пор нет информации, были ли у нас в Сабинских краях гусли, гусляры.

Несколько лет назад в нашем районе в рамках фестиваля “Иске Казан түгәрәк уен” с гуслями выступил художественный руководитель Центра татарской культуры (г. Йошкар-Ола Республики Марий Эл), заслуженный работник культуры Марий Эл и Татарстана Гарай Магсумзянов. Мы там впервые увидели гусли, и их необычное звучание

запомнилось. Ведь Гарай абый с удивительным мастерством сыграл татарские мелодии. С тех пор гусли стали появляться все чаще, устраивались конкурсы. Стали известны мастера из Арска, Балтасинского района, которые играли на гуслях. Нам посчастливилось познакомиться и пообщаться с Гараем Магсумзяновым, а также с фольклористом, этнографом, заслуженным деятелем искусств Республики Татарстан, изготовителем гуслей Геннадием Михайловичем Макаровым. Мы узнали, что и Гарай абый не только мастер игры на гуслях, но и мастер по их изготовлению. И загорелись мечтой приобрести у себя гуслей.

Наконец, в 2017 году, благодаря руководству района, отдела культуры, наша мечта сбылась, мы получили двое гуслей, изготовленные Гараем Магсумзяновым. Затем, получив советы у Гарай абый, мы начали изучение игры на гуслях самостоятельно. Выяснилось, что татарские гусли обладают разнообразными мелодическими возможностями и настроены на пентатонику, поэтому можно играть татарские народные мелодии. Звучание гуслей поистине пленяет каждого. Он уносит в какой-то сказочный мир, в волшебную страну, где каждый раз хочется слушать и слушать. У татар гусли издавна были в употреблении. Мы узнали, что они использовались для аккомпанемента певцам, исполнителям баитов, мунажатов, а также для исполнения инструментальных мелодий, и постепенно к игре на гуслях приобщились и дети. Они с большим интересом осваивают, даже поют под аккомпанемент гусляра. Открылась возможность для участия в конкурсах и фестивалях, с ансамблем стали добиваться успехов. Мы поставили перед собой цель и дальше не прекращать эту работу.

Волшебный звук гуслей соединяет нас со временем, когда жили наши предки, заставляет задуматься и почувствовать их мелодию. А понимание детьми этой волшебной мелодии, их любовь к гуслям вселяют надежду на будущее, веру в то, что молодое поколение, как в стихотворении Лены Шагирзян, мужественно хранит память о своем народе, народных традициях, которые передаются из поколения в поколение.






ESSENTIALS






«Звените,
старинные гусли»

***********************